| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

«2» август 2019 ел — № 141

**2018 елның 15 ноябрендәге 106 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 статьясындагы 2 өлешенең 1 абзацы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 15 ноябрендәге 106 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. **Карарның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:**

«Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Балтач муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Норма авыл җирлеге башлыгы — Р.Н.Шарипҗанов